| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 18.11.2022 | Казан ш. | № 604-178/кс-2022 |

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 №534-213/кс-2020 карарына үзгәрешләр кертү һәм «Химград» технополисы территориясендә су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык су агызуның үзәкләштерелгән системаларының технологик зонасында «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 №534-213/кс-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, оешма тарафыннан файдаланыла торган объектларны конкретлаштыру, 2023-2025 елларга

җайга салынулы оешманың салкын су транспортлауга, агынты су транспортлауга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Интеграция" катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 №534-213/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.08.2022 №129-27/кс-2022, 03.10.2022 №188-32/кс-2022, 03.10.2022 №189-33/кс-2022 карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2021-2025 елларга салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү турында»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020

№534-213/кс-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында һәм Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 №649-173/кс-2021 карарын көчен югалткан дип тану турында» 03.10.2022 №189-33/кс-2022 карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 №534-213/кс-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2022 № 604-178/кс-2022
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» ЖЧЖ өчен салкын суны транспортлаганга һәм агынты суларны транспортлаганга 2021 – 2025 елларга тарифлар

| №т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Салкын суны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| 1 | «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» ЖЧЖ | | | |
| 1.1 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән), су белән тәэмин итү челтәрләре «Химград» технополисы; «Арт Сити» ТК; «Вербный» ТК; «Весна» ТК; «GreenЛандия» ТК; «Изумрудный город» ТК; «Молодежный» ТК; «Победа» ТК; «Приволжский» ТК; «Сокольники» ТК; «2-ая Юго-Западная» ТК; «Казансу» ТК; | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 16,37 | 16,35 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 22,89 | 22,94 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 13,84 | 13,09 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 13,84 | 13,83 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 16,94 | 13,83 |
| | | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | 14,67 | 16,65 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 26,83 | 27,48 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | «Гармония» ТК;<br>«Современник» ТК;<br>«Три богатыря» ТК;<br>«Дом на Енисейской» ТК;<br>«Родина» ТК;<br>«Весна-2» ТК;<br>«Новые острова» ТК;<br><br>су агызу челтәрләре:<br>«Химград» технополисы;<br>«Арт Сити» ТК;<br>«Вербный» ТК;<br>«Весна» ТК;<br>«GreenЛандия» ТК;<br>«Изумрудный город» ТК;<br>«Молодежный» ТК;<br>«МЧС» ТК<br>«Острова» ТК<br>«Победа» ТК<br>«Приволжский» ТК<br>«Сокольники» ТК<br>«2-ая Юго-Западная» ТК<br>«Казансу» ТК<br>«Гармония» ТК<br>«Современник» ТК<br>«Три богатыря» ТК<br>«Весна-2» ТК<br>«Новые острова» ТК. | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 21,18 | 22,57 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 21,18 | 22,57 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 №534-213/кс-2020
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2022 № 604-178/кс-2022
карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы
«Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» ҖЧҖ өчен салкын суны транспортлаганга һәм
агынты суларны транспортлаганга 2021 – 2025 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Интеграция» катнаш челтәр компаниясе» ҖЧҖ | | | | | | |
| 1.1 | Салкын суны транспортлау | 2021 | 33 994,52 | х | - | 3,2 | 0,02 |
| | | 2022 | х | 1 | - | 3,2 | 0,02 |
| | | 2023 | х | 1 | - | 3,2 | 0,02 |
| | | 2024 | х | 1 | - | 3,2 | 0,02 |
| | | 2025 | х | 1 | - | 3,2 | 0,02 |
| 1.2 | Агынты суларны транспортлау | 2021 | 41 247,86 | х | - | - | 0,09 |
| | | 2022 | х | 1 | - | - | 0,09 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 | х | 1 | - | - | 0,09 |
| | | 2024 | х | 1 | - | - | 0,09 |
| | | 2025 | х | 1 | - | - | 0,09 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге